Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының уналтынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

27 октябрь, 2021 ел № 113

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, 2021 елның 4 октябрендәге гавами тыңлаулар беркетмәләрен һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрне исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең Генераль планын электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советын «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында» 2017 елның 5 маендагы 65/6 номерлы карарының үз көчен югалткан дип таныргa.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов